СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 251 от 31.08.2018
на № ________ от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
җирле үзидарә органы карамагындагы оешма
(учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи
бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына
китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык
барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү Тәртибен расларга (теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

2.1. җирле үзидарә органы карамагындагы оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләрен әлеге карар белән таныштырырга;

2.2. җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар (учреждениеләр) уставларына, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт килешүләренә ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесенең хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында җирле үзидарә органы җитәкчесенә хәбәр итү бурычын билгеләгән өстәмәләр кертергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Саба муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе Л.И. Шәйдуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль
Райны Башлыгы — Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
31.08.2018 ел, 251 номерлы карары белән

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы
карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи
бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки
китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык
барлыкка килү турында хәбәр итү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү процедурасын тәгаенли.
2. Әлеге Тәртиптә мәнфәгатьләр каршылыгы дигәндә вазыйфа биләп торган затның шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрү бурычын күздә тоткан, аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларын тиешле, объектив һәм гадел үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясарга мөмкин булган хәл аңлашыла.
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары һәм оешма (учреждение) уставы нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка китерү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.
4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (эшкә алучы вәкиленә) хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында, бу хакта билгеле булган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, хәбәр итәргә тиеш.
5. Хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында, ведомство карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында, хәбәр итү мөмкин булмаганда, әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән вакытка, хәбәрнамә, аны бетергәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, тапшырыла.
6. Хәбәр вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамә рәвешендә язма формада рәсмиләштерелә, (алга таба – хәбәрнамә).

Хәбәрнамәдә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) хәбәрнамә тотыручы ведомство карамагындагы оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) ведомствога караган оешма җитәкчесенең шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган) хезмәт бурычларын тиешенчә, объектив һәм гадел үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясарга мөмкин булган хәлнең тасвирламасы;

в) җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә вазыйфаи (хезмәт) бурычларын тиешле, объектив һәм гадел үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыкның квалификация билгеләре (җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе һәм (яисә) аның белән якын туганлыкта яисә үги туганлыкта булган затлар (ата-аналары, хатыны(ире), абый-энеләре, апа-сеңелләре, һәм

шулай ук хатыны(иренең) абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары һәм балалары һәм балаларының хатыннары(ирләре), оешма (учреждение) җитәкчесе һәм (яисә) аның белән якын туганлыкта яисә үги туганлыкта булган затлар мөлкәти, корпоратив яки башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән гражданнар һәм оешмалар тарафыннан акча, башка милек, шул исәптән милек хокуклары, милек характерындагы хезмәтләр, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яки нинди дә булса файда (өстенлекләр) рәвешендә керем алу мөмкинлеге).

г) башкаруга шәхси кызыксыну тискәре йогынты ясый яки тискәре йогынты ясарга мөмкин булган хезмәт вазыйфалары тасвирламасы;

д) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмый яисә килеп туган мәнфәгатьләр каршылыгын җайга сала алырлык тәкъдим ителгән чаралар;

е) хәбәрнамәне тутыру датасы;

ж) хәбәрнамәне тутырган затның имзасы.

7. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) 1 нче кушымта нигезендә төзелгән хәбәрнамә җибәрә.

8. Эш бирүче (яллаучы вәкиле) адресына килгән мөрәҗәгатьләр карау өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясенә (алга таба – комиссия) тапшырыла.

9. Мөрәҗәгатьләрне теркәү әлеге Тәртипнең 2 нче кушымта белән тәкъдим ителгән хәбәрнамәләрне теркәү жу́рналында комиссия секретаре тарафыннан башкарыла.

Комиссия секретаре хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш. Конфиденциаль мәгълүматны таратуда гаепле зат Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, башка җаваплылыкка тартыла.

10. Теркәү турында тамга белән хәбәрнамә күчермәсе Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма җитәкчесенә хәбәрнамәләрне теркәү журналында теркәп кул куйдырганнан соң, яисә почта аша, алу турында хәбәрнамә белән җибәрелә.

11. Хәбәрнамәләрне беренчел карау барышында Комиссия хәбәрнамә җибәргән затлардан хәбәрнамәләрдә бәян ителгән шартлар буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрергә хокуклы.

12. Хәбәрнамәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне беренчел карау барышында алынган хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар, хәбәрнамәләр кергән көннән алып, җиде эш көне эчендә, комиссия утырышына тапшырыла.

Әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләр җибәрелгән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар эш бирүчегә (яллучы вәкиленә) хәбәрнамә кергән көннән 45 көн эчендә комиссиягә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән артыкка түгел.

13. Комиссия хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча Комиссия турында Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) җибәрә.

14. Эш бирүче (яллучы вәкиле) комиссия тарафыннан хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип танырга;

б) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксыну

мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар үтәлмәде дип танырга.

14. Әлеге Тәртипнең 14 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрә яисә чаралар күрүне тәэмин итә.

15. Әлеге Тәртипнең 14 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, җирле үзидарә органы карамагында оешма(учреждение) уставында һәм хезмәт килешүендә каралган дисциплинар җәза бирелә.

Хәбәрнамә һәм хәбәрнамәне карау белән бәйле башка материаллар Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең шәхси эшенә теркәлә.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү Тәртибенә
1нче кушымта

Тәкъдим ителгән үрнәк

_______________________________________
(вәкаләтле орган рәисенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты рәисенә) (кирәклесен сайларга)
_______________________________________
(Ф.И.О.)
от ____________________________________
(Ф.И.О., должность)

# ХӘБӘРНАМӘ
## вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуларым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган шартлар: ______________________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксынучанлык йогынты ясый яки йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар: ______________________________________________________________.

Әлеге хәбәрнамәне караганда комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

"__" ________ 20__ г. ______________________________ _______________________
(хәбәрнамә бирүченең шәхси имзасы) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү Тәртибенә
2нче кушымта

Тәкъдим ителгән үрнәк

**Эш бирүченең (эшкә яллаучының)
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамәләрне теркәү журналы**

| N п/п | Хәбәрнамәне теркәү номеры | Хәбәрнамәне теркәү датасы | Хәбәрнамә тапшырылды | | Хәбәрнамә теркәлде | | | Хәбәрнамәнең күчермәсен алу (күчермәне алдым, имза) яисә хәбәрнамә күчермәсен почта аша җибәрү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ф.И.А.И. | вазыйфасы | Ф.И.А.И. | вазыйфасы | имза | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |